Муниципальное бюджетное дошкольное образовательное учреждение
«Детский сад №67 комбинированного вида с татарским языком воспитания и обучения» Советского района г. Казани РТ

# Сөйләм үстерүдә бармак уеннарының әһәмияте.

*воспитатель:*

*Шигабиева Гульлназ Фаридовна*

Мәктәпкәчә тәрбия бирү учреждениеләренең төп бурычлары балаларның акыл үсеше һәм сөйләм телен үстерү. Бик еш балаларның сөйләм теле үсеше артта кала. Сөйләм теле үсешен, гадәттә, турыдан-туры баланың өлкәннәр белән аралашуына бәйләп бәялиләр.

Әгәр баш миенең төзелешенә күз салсак, хәрәкәтчән сөйләм өлкәсе, хәрәкәтләнү өлкәсе белән янәшә урнашканын, аның бер өлеше булуын күрербез. Хәрәкәт проекциясенең өчтән бер өлешен сөйләм зонасына якын урнашкан кул чуклары проекциясе алып тора. Шуңа күрә бармаклар белән нәфис хәрәкәтләр ясауның баланың сөйләмен үстерүдә әһәмияте бик зур. Бармак хәрәкәтләре үсеше дәрәҗәсе сөйләм дәрәҗәсе белән тәңгәл. Һәр бармагы белән аерым хәрәкәт ясый алган бала әйбәт сөйләшә. Һәм киресенчә: бала сөйләшә белмәсә, аның бармаклары барысы бергә бөгелә-турая, киеренке яисә “сыек буынлы” була. Шуңа күрә, баланың бармаклары иркенләп хәрәкәтләнмәсә, аның сөйләмен үстерү мөмкин түгел.

Бармак уеннары баланың акыл, фикер эшчәнлеген үстерүдә, дөньяны танып белергә өйрәтүдә бәя биреп бетергесез тәрбия чыганагы, чөнки әлеге уеннар аша бала әхлакый – этик кагыйдәләр белән дә таныша башлый. Бармак уеннары – өлкәннәр белән балаларның үзенчәлекле аралашу, күңел ачу чарасы. Бишек җырлары баланы тынычландыру, юату өчен кулланылса, бармак уеннары, киресенчә, баланың күңелен күтәрү, кәефен яхшырту, көлдерү чарасы булып тора. Ул баланың бармак хәрәкәтләре үсешенә дә ярдәм итә. Димәк, бармакларның сөйләм үсешенә дә тәэсире зур. Бармаклар белән төрле күнегүләр ясау, аларны төрлечә хәрәкәтләндерү – баланың сөйләмен үстерүдә уңай шарт булып тора. Әлеге күнекмәләрне инде балага алты-җиде ай вакытты башларга кирәк. Моңа кул чукларының һәр өлешен бик яхшылап массажлау кирә. Аларны язу, сыйпау көн саен ике-өч минут дәвам итәргә тиеш. Күнегүләр дә бик гади – турайтып уйнау. Алар һәр көн 2-3 минут дәвамында ясарга кирәк.

Безнең халыкта бармак уеннары да бик күп бит. “Атка печән кем сала?”, “Качкан бармакны тап!”, “Тычкан-төлке чабышы”. Аларның кайберләрен

уйнаганда без җырлар җырлыйбыз, такмак-такмазалар әйтәбез. Сүзләрне әйткәндә, бармакларны бер-бер артлы бөгеп барабыз. Әгәр балалар өчен күнегүләрне башкару кыен икән, өлкәннәр, бармаклар тиешсез вакытта бөгелмәсен өчен, аларны тотып тора.

Балаларның бармакларын ныгыту өчен “Бармак театры” оештыру бик файдалы. Тик шуны истә тотарга кирәк: бармак уеннары биш минуттан озаграк булмасын, бу аның сөйләм функциясен стимуллаштыру өчен бик җиткән.

Кул чукларының хәрәкәтен үстерү язу хәрәкәтләренә, рәсем ясарга әзерлек эше дә әле ул. Кул һәм бармаклар хәрәкәтләрен үстерү өчен үз массаж, сурәтләү сәнгате шөгыльләре (әвәләү; рәсем; аппликация; кул хезмәте; кәгазьдән, картоннан, агачтан, тукымадан, җептән кул эшләре), шнурлау, төймәләү кебек эшләр уңай йогынты ясый. Бармакларның хәрәкәтчәнлеген үстерү буенча эшне даими рәвештә алып барырга кирәк, чөнки шул вакытта гына ул файдалы була. Күнегүләр балаларны ардырмаска һәм күтәренке кәеф белән эшләнергә тиеш.

Бармак моторикасын ныгыту өчен үз эшемдә бармак уеннарына аеруча зур игътибар бирәм. Түбәндә балалар куллана торган бармак уеннары тәкъдим итәм.

1 . Без кәбестә турыйбыз, (бармак чуклары белән кисү хәрәкәтләре

ясау)

Кишерен дә уабыз, ( кулны йодрыклап, уу хәрәкәтләре ясау)

Тозларны да сибәбез, (тоз сибү хәрәкәте)

Кәбестәне кысабыз. ( учларны йодрыклау һәм ачу хәрәкәтләре)

2. — Бармак, бармак,

Кайда булдың?

— Бу абый белән

Урманга бардым.

Бу абый белән

Кырда йөгердем.

Бу абый белән

Ботка ашадым.

Бу энем белән

Җыр җырладым.

3. Яшелчәләрне истә калдырыр өчен бармак уены.

Бу бармак- кабак,

Бу бармак- борыч,

Бу бармак- кишер,

Бу бармак- кыяр,

Бу бармак - суган.

Яшелчә быел уңган,

Бакчабызда бар да бар!

Шунсы кызык, болар барсы Кәрзингә ничек сыйган?

Бу бармак- чөгендер,

Бу бармак- сарымсак, Бу бармак- баклажан,

Бу бармак- помидор, Бу бармак- бәрәңге.

Бик тиз җыеп бетердек, Ярый әле өлгердек.

Җәйге яңгыр килеште, Яшелчәләр тиз үсте.

4. Бу бармак – бабай,

Бу бармак - әби,

Бу бармак - әти,

Бу бармак - әни,

Бу бармак – бәби,

Аның исеме – чәнти.

Ясалган күнегүләр кул чугы һәм бармаклар ныгуга китерә, ә бу үз чиратында киләчәктә язу күнекмәләрен җиелерәк үзләштерергә ярдәм итә. Шуны истән чыгармаска кирәк: вак моторикалы ныгытуга файдалы булсын өчен, бармак уеннары һәрвакытта да чиратлап ике кул белән кабатлана.

**Кулланылган әдәбит:**


1. Татар халык иҗаты (балалар фольклоры) Я. Г. Абдуллин, И. Н. Надиров, М. Г. Госманов. Казан, Татарстан нәшрияте 1993 ел.О.В. Узорова, Е.А.
2.Нефедова «Пальчиковая гимнастика» – ООО М. Изд-во Астрель», 2007.